**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ**

**КАРАР**

«01» июль 2024 ел № 42/2

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 марттагы 2/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы»Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 марттагы 2/1 номерлы карары белән расланган (барлык үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктта:

8.11 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

8.17 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

8.20 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.20. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында карар, әлеге пунктның 8.13 пунктчасында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чинын бирергә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки вазифаи затына барлык кирәкле документлар белән класс чины бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»;

1.2. 13 пунктта:

13.5 пунктчасына «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

13.7 пунктчасына «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.3. 15 пунктның 15.7 пунктчасында:

«дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге икенче абзацны өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

1.4. түбәндәге эчтәлектәге 16.1 пунктын өстәргә:

## «16.1. АНКЕТА БИРҮ, АНКЕТАДА БУЛГАН МӘГЪЛҮМАТНЫ ҮЗГӘРТҮ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ ҺӘМ МОНДЫЙ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ТИКШЕРҮ

16.1.1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тапшыра.

16.1.2. Муниципаль хезмәткәр эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

16.1.3. Анкета формасы, шул исәптән анда кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм срогы Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

16.1.4. Анкетада булган мәгълүматлар эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле яки аның вәкаләте заты карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, запрослар җибәрү юлы белән башкарыла. Тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнары һәм оешмалары соралган мәгълүматны әлеге запросны алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

1.5. 29 пунктның 29.1 пунктчасынатүбәндәге эчтәлектәге икенче абзацны өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар нәтиҗәсе дип танылса икән, җаваплылыктан азат ителә.»;

1.6. 30 пунктта:

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт үткән чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының мәгълүмати ресурсларында саклау өчен мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (шәхесләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру;»;

11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

түбәндәге эчтәлектәге 11.1 өлешен өстәргә:

«11.1) дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматка билгеләнгән формада рөхсәт рәсмиләштерү;»;

31 пунктның 31.10 пунктчасында беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Максатчан укыту турында шартнамә төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белемне беренче тапкыр алучы һәм уку яки башка укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган шартнамә буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советының законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

ТР Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина